СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

3 сентябрь, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 98 (8110) | Бәясе билгеләнгәнчә

Чәнләды көмеш көңгырау чакырып дәресләргә...

Мәктәпкә - район хакиме бүләге

Сер түгел, ярдәмче интернат - мәктәп район җитәкчелеге тарафыннан игътибарга тиенгәне булмады. Багъланышы, укыту спецификасындагы үзгәлеге сәбәп булгандыр инде моңа. Шуңа да быелгы Белем бәйрәменә район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллиннын килүе аңа үзенчәлекле ямь, бизәк, өлкәннәр, шулай ук балалар күңеленә сөенеч өстәде. Үсеш буенча артта калучы һәм

ятимнәр, бу учреждениедә тәрбияләнүче барлыгы 170ләп бала янына буш кул белән генә килмәгән булып чыкты район җитәкчесе: мәктәпкә чит илдә эшләнгән төсле телевизор алып килгән. Ә чын күңелдән сөйләгән сүзләре, ихластан әйткән теләкләре... Мәктәпнең тантана үткән кысан коридорлары кинәеп, сүрән кояш караган тәрәзәләре яктырып киткәндәй булды.

- Кайда гына булсагыз да, белем, тәрбия биргән мәктәбегезне онытмагыз. Хезмәт аркылы килгән хөрмәт кенә мораль һәм матди канәгатьләнү бирә, - диде ул педагогия коллективын һәм балаларны бәйрәм белән котлап һәм соңгы елларда балаларга белем бирү, тәрбияләү буенча зур үзгәрешләр кичергән бу учреждениене аерым игътибарга алып, ярдәм итәсенә ышандыргач, зал балаларның бердәм «рәхмәт» сүзләренә, көчле алкышларга күмелде.

Хәер, бу көн әлеге чарада катнашучы күпләр күңелендә матур тәэсир калдырды. Ундүрт ел буена бөтен укыту - тәрбия эшенә эзлекле җитәкчелек итүче ветеран - педагог, оста җитәкче В.Е.Ефимов, аның урынбасарлары Э.Х.Абдуллина һәм Н.З.Миннебаева, укытучы Р.И.Гыйрфанова, район мәгариф бүлеге мөдире В.М.Камалованың балаларга яңа уку елы башлану уңаеннан җылы котлаулары, изге теләкләре, тулаем зал алкышлары астында беренче сыйныфка укырга керүчеләргә бүләкләр тапшыру, җырлар, шигырьләр, кочак - кочак чәчәкләр, шатлык - сөенеч тулы күзләр - бу якты бәйрәм мәктәп педагоглары, укучылар күңелендә шулай истә калыр.

Р.ГИНЯЕВА.

Бәйрәм «Эскимо»сы

Авыл тормышы - яшьләр кулында. Синдряков исемендәге КХА җитәкчелеге бу турыда бер генә минутка да онытмый. Әле менә беренче сентябрь көнне үткәрелгән Белем бәйрәмендә дә бу ачык чагылды. Агролицей җитәкчесе Ю.И.Ивановның укучыларны котлавыннан соң ук сүз ассоциация җитәкчесе С.И.Белогубовка бирелгәч, җитәкче балаларны тәбрикләде һәм комбайнчы ярдәмчеләре булып эшләүче егетләргә, җәй буе шикәр чөгендере үстергән кызларга кул сәгатьләре тапшырды. Гомумән, җәйге каникуллардан авыл хуҗалыгы производствосының башка тармакларында хезмәт куйган калган яшьләрнең дә күңелләрен күрделәр җитәкчеләр: аларның берсе генә дә бүләксез калмады.

Укучылар хуҗалык администрациясе сюрпризына да бик сөенделәр. Баксаң, ассоциация нәкъ бу бәйрәмгә атап, балаларга кап - кап тондырма кайтарткан икән. Бүләк рәвешендә таратылган «Эскимо»га балалар бик шатландылар: кеше күңелен, аеруча балалар күңелен күрү өчен күп кирәкмени?! Бүтенге финанс кытлыгы заманында җитәкчеләрнең барысының да мондый адым ясарга күңелләре җитмәве генә кызганыч.

Н.ЛАЗАРЕВА.

Үз белгечләребез булыр

Мәктәпләрнең бик сирәгендә генә музыка, рәсем дәресләрен махсус әзерлекле белгечләр укыта. Бу мәгариф бүлеген күптәннән борчый килә иде. Быел, нинаять, Лениногорскидагы педагогия училищесының рәсем һәм музыка укытучылары әзерләү бүлекләренә районнан 7шәр укучы укырга керде.

Киләчәктә бу эшне эзлекле итәргә дигән ният бар. Шуңа быел 8 нче мәктәп базасында сәләтле укучыларны рәсем сәнгате серләренә өйрәтү максатыннан изостудия эшли башлаячак.

«Урак - 97» пресс - үзәге хәбәр итә

Район авыл хуҗалыгы идарәсеннән алынган оператив мәгълүматлардан күренгәнчә, 2 нче сентябрьгә бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культураларның 38.800 гектары, ягъни барлык мәйданнарның 79 проценты теземнәргә салынды. Игеннәр 36.178 гектарда суктырылды. Бу - барлык мәйданнарның 74 проценты кадәр. Уракны тәмамлаган ике хуҗалык - «Дуслык» һәм «Лесная Поляна»та якын көннәрдә Хафизов исемендәге КХА да кушылачак. «Татарстан», «Заветы Ильича», Муса Җәлил исемендәге, «Рассвет», «Сөлчә» хуҗалыкларында да эш әйбәт бара.

МСО, нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларында, «Заря», «Якты Күл» ассоциацияләрендә исә урып - җыю эшләренең темпы бик түбән әле.

2 нче сентябрьгә 15.269 гектар мәйданда тунга сөрү үткәрелде. 10.984 гектар, ягъни планлаштырылган барлык мәйданнарның 66 процентында уҗым чәчелде.

Уныш жыелган 27.85 гектардан салам жыелды һәм тулаем район буенча аның запасы 29.030 тонна тәшкил итә.

•Басылганга кире кайтып

Үлчәдемме - үлчәдем генә...

Дәүләткә озатыла торган ашлыкның урында һәм элеваторда үлчәгәндәге авырлыклары чагышмау турында әле үткән санда гына язып чыккан идек. Кызганычка каршы, бу мәсьәләдә хәл һаман да унайга үзгәрми.

Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм аның сыйфаты буенча дәүләт инспекциясеннән хәбәр итүләренә караганда, мондый хәл көн дә кабатлана тора. Мәсәлән, 29 августта Хафизов исемендәге хуҗалыктан килгән бер машина ашлыкның авырлыгы накладнойда күрсәтелгәннән 1 тонна 280 килогрммга, Мичурин исемендәге хуҗалыкның бер машинасыныкы 2 тоннага диярлек, нефтебаза ярдәмче хуҗалыгыннан һәм «Киекле»дән берәр машинаныкы 738 һәм 836 килограммга артык, «Үрнәк»нең бер машинасында 970 килограммга артык, икенче берсе, киресенчә, 550 килограммга кимрәк чыккан. Ә «Агрохимсервис» һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларыннан, «Родина», «Игенче»дән ул көнне ашлыкны үлчәми - нитми генә озатканнар. Соңыннан ул ашлыкның ничек очына чыгарга уйлый торганнардыр.

Монда төп сәбәп урыннардагы үлчәүләрнең төзек булмавында. Инспекция һәм элеватор белгечләре катнашындагы комиссия Мичурин исемендәге, Кузнецов исемендәге хуҗалыкларда үлчәүләрнең кләймәләнмәгән булуын, кайбер үлчәүләрнең угы буш көенә «ноль»дә тормавын ачыклаган. «Родина», «Төрнәс» хуҗалыкларындагы үлчәүләр дә «ноль»гә көйләнмәгә, төрле сәбәпләр аркасында иркен йөрми булып чыкты. «Чирмешән»нең Кәкре Атау бүлекчәсендәге үлчәү дә жимерек, «Заря»да исә машиналарны буш көенә үлчәп мәшәкатьләнмиләр икән.

Кызганычка каршы, элеваторның үзендә дә үлчәүләр (үлчәүчеләр дип анла) бик үк гадел түгел булып чыккан. Шул ук көнне тикшерү үлчәүләрнең берсенең угы 40, икенчесенеке 10 килограмм бүленешкә авышкан булып чыккан. Нәтиҗәдә бер сәгать эчендә шул үлчәүләр аша узган 19 машинаның ашлыгы гына да 3901 килограммга кимрәк чыгып, кара исәп белән генә дә элеваторга 3 миллион 358 мең 800 сумлык файда ясалган.

Дәүләт инспекторлары элеватор лабораториясендә ашлыктан анализ алганда кайбер «төгәлсезлекләр» жибәрелүгә дә тап булгалыйлар икән. Әйтик, моннан элек «Татарстан» хуҗалыгыннан китерелгән «Труженик» сортлы борчакны рядовой борчак сыйфатында кабул итә калган булсалар, хуҗалыкка ашлыкның арзан хакка китүе аркасында 2.361 мең сум, сортсыз кабул ителгәнлектән 7.437 мең сум, барлыгы 10 миллион сум чамасы акча керми каласы иде. Кыскасы, быел ашлыкның ишле булуы да аның исәбен алуга игътибарны йомшартты. Әмма һәр жаваплы кеше янына аерым бер тикшерүче куеп булмый бит инде, һәркемнен үзендә дә намус дигән нәрсә булырга тиештер.

Р.МУЛЛИН.

ФАТИХ СИБАГАТУЛЛИН:

ҮЗЕМ ӨЧЕН ГЕНӘ ТҮГЕЛ



Хакимнәр житәкче кәнәфиенә гомерлеккә утырмыйлар. Килләләр, китәләр. Пенсиягә озатылалар, яисә югарыдагылар фәрманы белән урыннарыннан бушатылалар, яңа вазифага билгеләнәләр.

Октябрь районында партия райкомының беренче секретаре Габбас Гыйрматдинов лаеклы ялга Социалистик Хезмәт Герое йолдызын тагып китте. Аны алыштырган яшь, көчле, төрле яңалыклар кертергә очынып торучы Хәлил Морадыймовка исә талантын тулысынча ачарга мөмкинлек бирелмәде: 5 елдан соң аны өенә җәяү кайтарып жибәрделәр. Заманында гаилә дусты булып йөргән яңа башлык Шамил Кашапов хәтта аны эшкә урнаштырырга да ашыкмады. Әмма Алланың кашка тәкәсен эләктерүче сортында ул озак йөри алмады. Дәүләт Советы сессиясе мөнбәреннән исеме төрле килешләрдә төрләндерелгәч, югарыга шикаятләр агыла башлагач, урыннан тиз бушатылды. Аны төрле семинарларда күрсәткән яңалыклары белән бөтен Россияне шаккатырган Татарстанның авыл хужалыгы һәм азык - төлек министры Фатих Сибагатуллин алыштырды.

Менә ул район оешмалары, хужалыклары житәкчеләре белән чираттагы киңәшмәсен үткәрә. Министр чагындагы кебек эшлекле, житди, катгый сөйләшә. Кайберәүләрне урыннарыннан күтәрә дә әйтеп куя: «Хәлдән килмәгәч, нишләп вәгъдә бирәсез соң? Ни өчен халыкны алдыйсыз? Аркагыздан сыпырып мактап йөргәнне көтәсезме? Тагын бер кат исегезгә төшерәм: эшләмичә тәртип урнаштырып, баеп булмый...»

Житәкчеләрнен исем-фамилияләре телгә алынгач, тәнкыйть сүзләреннән соң залда берникадәр тынлык урнашкач, әйтелгәннәр тәэсире бермә - бер арта.

Айга бер тапкыр уза торган мондый киңәшмәләрнен кайтавазы алар белән хезмәт коллективларына да иярәп кайта, төрле фикерләр уята. Күрәсен, шундый кин мәйданнарда элиталы орлык чәчеп, барлык хужалыкларда нәселле терлек үрчетеп, авыл хужалыгына алдынгы технология кертеп булмыйдыр.

Әлеге таләпчән, үз дитәненә ирешә торган Ф.Сибагатуллин - Октябрь районы өчен читтән, Казаннан килгән кеше. Әмма шулай да, әле бер ел да эшләмәвенә карамастан, биредә аны үз итеп өлгергәннәр. Кыска гына вакыт өчендә ул моңа ничек ирешкән соң?

- Фатих Сәүбәнович, сүзне шуннан башлыйк әле: сезне Татарстан халык депутаты итеп сайлау көнендә сайлаучыларның 98,4 процценты катнашкан. Аларның 99,3 процценты сезне яклап тавыш биргән. Тиз арада сайлаучыларны ничек шулай үз ягыгызга аудара алдыгыз?

- Программамны ошатылар. Күрешкәннән соң ук газ кертүне тизләтүнен, Чирмешән елгасы аша күпер сала башлауның, мәчет һәм чиркәү ачылуның... шаһитлары булдылар. Өч айда аэропортта яңа бина күтәрелде. Самолетлар ярты бәягә оча башлагач, Казанга юл якынайды, халыкның яңарышларга ышанычы артты.

- Кешенең теңкәсенә тигән сусызлык мәсьәләсен дә санаулы көннәрдә хәл иткәнсез икән?

- Норлатта 17 меңнефтьчене суга тилмертү ул жинаятькә тин. Алар яшәгән өйләргә чүлдәге шикелле, иртән һәм кичен фәкать икешәр сәгать кенә су бирүне анлап та, яклап та булмый. Житмәсә, алар чиләк тотып кран янында сакта тора торган вакытта өйләрендә дә булмыйлар. Автобусларга утырып Аксубай, Яна Чишмә, Чирмешән якларына - буровойга чыгып китәләр. Сусызлыктан балалар интегә. Жир мае озак еллар суыртылганга күрә, шифалы чыганак таба алмыйлар, янәсе. Имеш, торбаларны Базарлы Матактан ук тартмыйча чара юк. Баксаң, артезиан коесын үзебездә дә казып була икән.

- Соңгы вакытларда Октябрь районы кеше үтерүләрдән тетрәп торды. Әйтегез әле: вәхшиләр тотылдымы?

- Кызганыч, 4 үтерештә 10 кешенең гомере киселде шул. Халык урамга чыгарга курка башлады. Аптырагач, Татарстан эчке эшләр министры Искәндәр Галимовка мөрәжәгать итәргә туры килде. Ул ин тәжрибәле тикшерүчеләрен жибәрде. Нәтижәдә жинаятьчеләр кулга алынды, жәзага тартылды.

- Иртәнге сәгать дүрттә авылларга чыгып чабуыгыз да хакмы?

- Октябрь районына килүне - үтеп чыгалмаслык караурманга эләгү белән тинләсәм, хата булыр. Мондагы тормыш агышы хакында электән үк хәбәрдармын. Элеккеге беренче секретарь Габбас Гыйрматдинов белән 1980 елдан ук таныш идем. Аны алыштырган Хәлил Морадыймовны да беләм. Житәкче органнарда армый - талмый эшләүче ирле - хатынлы Любовь һәм Адлер Газизуллиннар белән дә еш очраштым. Әмма хужалыклардагы чын хәлне белү өчен танышлар сүзенә колак салу гына житми. Урынга барырга, карарга, күрергә кирәк. Шунсыз - үзен эшләмәсән, кешене эшләтеп булмый.

Менә терлекчелекне генә алыйк. Көтүнен вакытында чыкмау очраклары бар, азык китерү тоткарлана, су юк, тоз куелмаган, авыру хайван янында веттабиб күренми. 1 тонна сөтнен 1 миллион сум акча китерүен онытып жибәрәләр. Менә кайда ул хезмәт хакы?!

- Сез Татарстан милли спорт төрләре һәм халык уеннары федерациясенә житәкчелек иткәндә, ярышларның популярлыгы артты. Аеруча татарча көрәш жанланды. Әмма Октябрь районы, дөресен әйтергә кирәк, әлеге мәртәбәле бәйгеләрдән читтә калып килде. Сәбәп нәрсәдә соң: ара еракмы, Рәшит Сәмигуллин кебек пәһлеваннарга каршы чыгарга батырчылык итүче егетләр юкмы?

- Чулпан авылында әнә классик көрәш буенча алгы урыннарны алучылар бар. Хәзер алар татарча көрәшкә дә игътибарны арттыралар. Башкалар да тик тормыйлар. Әмма берничә атна шөгыльләнеп кенә Татарстан күләмендә танылып булмый. Моңа еллар кирәк. Ике елдан соң мәйданда Октябрь районы көрәшчеләре үз сүзләрен әйтерләр дип уйлыйм.

Норлат йөзүчеләре дә бәйгедә катнашмый калмаслар. Менә нефтьчеләр тырышлыгы белән бассейн ачылды. Ул Европа стандарты таләпләренә жавап бирерлек корылма.

- Колбаса цехыгыз турында исә: «Дөнья стандарты таләпләренә жавап бирерлек»,- дип сөйлиләр.

- Жиһазларны Германиядән килгән белгечләр куя. Әмма начар иттән яхшы колбаса ясап булмаганлыкны да онытырга ярамый. Шуна күрә дунгыз симертү буенча агрофирма оештырдык. Монда малларның баш саны 10 меңгә житте, киләчәктә 30 мең булачак. Аларны үзләрендә житештерелгән арзан азык белән тукландырачаклар.

- Ашлык суктыру өчен ин камил 10 комбайнның Америкадан ук кайтарылуы дөреслеккә туры киләме? Әллә бераз арттырып жибәрәләрме?

- Норлат жирендә урып - жыюда яңалык кертүе кыен. Чөнки Хәлил Морадыймов хакимият башлыгы булганда «кыргый отряд»лар оештырып күрсәткән иде. Ягъни, ул югары житештерүчән 5 «ДОН» комбайнын «Сельхозтехника» карамагына бирде дә аларга аерым «КамАЗ» машиналары беркетеп, артта сөйрәлүче хужалыкларга чыгарып жибәрде. Аларны төнгә чаклы эшләтеп, урып - жыюны ничек итеп вакытында тәмамлап булганлыкны күрсәтте. Һәр комбайнга - икешәр комбайнчы беркетү дә зирәклек. Үзара рәхәтләнеп ярышачаклар. Күпме эшлиләр шул хәтле акча алачаклар.

«Кыргый отряд» карамагында менә Американың «Аксил - Флоу» комбайннары. Бездәге «Дон»нар - 800 млн. сум торса, көнбатышныкылар 1 миллиардка төшә. Әмма 150 еллык тарихлы әлеге техника житештерүчәнлеге буенча Россиянен 3 кыр корабын алыштыра. Ә уңайлык? Кабинасы - жинел машиныкы кебек, кондиционеры да бар. Кабарынкы тәрәзәсе күз күрешен 30 процентка яхшырта. Югалтусыз эшләү өчен чын мәгънәсендә могжиза анда!

«Татдорстрой» карамагындагы юл салу комбайнына да күз тимәсен. Анысы да Американыкы. Өч километр озынлыкка жеп тартасың да эшләү өчен фәрман гына бирәсең. Ком, таш, асфальт 70 сантиметр калынлыкта түшәлеп бара.

- Жыелышта искәрткәнегезчә, Октябрь районында сезнең туган - тумачаларыгыз юк. Кемнәргә таянасыз?

- Беренче чиратта әлбәттә, халыкка. Аннары дөнья тоткасы булган лидерларга. Кемнәргәме? Әйтик, элеккеге хакимият башлыгы Хәлил Морадыймовка. Үзем эшкә алыну белән аны «Сельхозхимия» генераль директоры итеп билгеләдем. Чөнки базар шартларында «Сельхозтехника»сыз яшәп булса да, жирне химияләштерүсез уңышка исәп тотып булмый. Ни өчен дигәндә, яз чәчеп, көз урып кына ашлык күләме гектардан 15 центнердан артмый. Ә бүген ул 40 центнер кирәк. Моның өчен исә жирдән файдалана белү зарур. Туфракны ашлау, үсемлекне авырудан һәм бөжәкләрдән саклау мәслихәт. Һәр хужалыкта бу эшләрне фәнни нигездә оештыру таләп ителә. Уңышның серешунда.

Социаль мәсьәләләр буенча урынбасар Флера Ногманова да ышаныклы таяныч. Ул заманында мәктәп директоры булган. Колхоз рәисе вазифасын башкарып, хакимияттә эшләгән. Ә власть яңаргач, сәясәт корбаны булып 2 ел эшсез торган. Мондый кадрны юкка чыгарырга ярыймыни?!

Саный китсән, алар әле тагын бар.

Октябрь районы хакимияте башлыгы Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин менә ничек фикер йөртә. Гомерне сүгеләп үткәрүгә караганда, мактап уздыруны артыграк күреп «Үзем өчен түгел бит» - дип халыкка санап бетермәслек яхшылыклар эшли. Шул ук вакытта башлык кылган гамәлләрен үзенеке генә итеп күрсәтү ягында да түгел. Жай чыккан саен. Татарстан читенә илтеп ташлап, онытмаганнары, булышлык күрсәткәннәре өчен республика житәкчелегенә рәхмәтен житкерә.

Сәүбәнлашыр алдыннан район башлыгы бер мәзәк сөйләп алды. Шулай бер мәжлестә өстәлгә кысла пешереп чыгарганнар икән. Әмма таба чыжлап куыруларына карамастан, алар селкенеп торалар ди. Бу ни хикмәт инде. Соңыннан сернен хужа ачкан өстәлгә жанлылык биреп торсын өчен ул пешкән кыслалар астына тере кысла куеп калдырган икән.

Кинояне аңладыгызмы? Димәк Казаннан Октябрь районына жибәрелгән Ф.Сибагатуллин да урындагыларны селкетеп хәрәкәтләндереп, жанландырып торучы. Ягъни ул эш кешесе.

ХӘМЗӘ БӘДРЕТДИНОВ,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.
(«Шәһри Казан» газетасыннан).

Тарих битләрен ачкач

(мәктәп директоры хатирәләреннән)

Быел Якушкинода тагын ике истәлекле дата - урта мәктәп ачылуның 60 еллыгы һәм земский башлангыч мәктәбенен 101 еллыгы билгеләп үтелә.

Башлангыч мәктәпнен бер класслы бинасы Төрнәс авылы павытынын әнисе Сафа-товның I гильдия сәүдәгәре Аносова акчасына салына.

1896 елда Якушкино мәктәбендә 50 укучы белем алды, аларның 8се - руслар, 42се - чувашлар.

Александр Иванович Иванов - чуваш милләтле кеше, ин беренче укытучы була. Икенчесе - 1897 - 1898 нче уку елларында Казан үзәк керәшен - татар мәктәбен тәмамлаган, керәшен татары Порфирий Никитич Смирнов укытучы булып эшли башлый. 200 сум хезмәт хакы, мәктәптә фатиры була аның.

1913 елгы мәгълүматлар буенча , чыгышы белән Чувашстаннан Федор Терентьевич Терентьев Якушкино мәктәбе мөдире булып тора, ә икенчесе - Василий Николаевич Корбанов. 1927 елда Якушкинога педтехникум тәмамлап, 24 яшьлек укытучы Дмитрий Илларионович Ларионов килә.

1930 елда «Новый путь» колхозы инеш янында 4 класслы, салкын гомуми коридоры булган, валчыклы салам япмалы мәктәпкә жайлаштырылган бина төзи.

1934 елда биредә крестьян яшьләре мәктәбе ачыла, бер елдан ул тулы булмаган урта мәктәп итеп үзгәртелә.

1936 елны «Новый путь» колхозы идарәсе, түбәсе йомычка белән япкан ике катлы агач мәктәп сала. Бер елдан соң, 1937 елның 20 августында биредә районда беренче чуваш урта мәктәбе ачыла. Анын директоры итеп бу юлларның авторын билгелиләр.

Ф.МИХЕЙКИН.
Казан шәһәре.

Салкыннарга кадәр өлгерәсе

(Норлат җирле үзидарә Советы утырышыннан)

Норлат җирле үзидарә Советының шәһәр предприятиеләре, оешма һәм учреждениеләре җитәкчеләре катнашында узган кинәйтелгән утырышының максаты шәһәрнең җылылык - энергетика хужалыгын алда торган ягу сезонына вакытында әзерләп өлгертү өчен башкарылган эшләрне бәяләп, тиз арада тагын ниләр эшләргә кирәк һәм мөмкин булганлыгын ачыклаудан гыйбарәт иде.

Мәсьәләнең никадәр җаваплы икәнлеген кабатлап торасы юктыр, чөнки җылылык белән тәэмин итүдә кечкенә генә өзеклек тә нинди аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин икәнлеген былтыр МСО микрорайонында килеп чыккан авария бик ачык күрсәтте - предприятиенең җылылык хуҗалыгы көтелмәгән хәлләргә әзер булмау сәбәпле берничә йөз фатир, йөздән артык шәхси йорт кышның үтә салкын чагында озак кына вакытка җылысыз калды. Ә шәһәрнең 23 котельнядан җылытылуын исәпкә алсак, ягу сезонына никадәр катлаулы хуҗалыкны әзерләргә кирәклеге аңлашыла. Шунысы игътибарга лаек, быел алар чираттагы ягу сезонына нигездә әзерләнгән. Алардагы 20 казан ремонтланган (шуның җидесе - җылылык челтәре предприятиесе котельняларында), барлыгы 11, шул исәптән элеваторда 3 һәм Норлат җылылык челтәре предприятиесендә 3әр, АТПда һәм райпоның хәзерләүләр конторасында икешәр, геофизикада бер казан тулысынча алыштырылган. Тугыз котельня газ, шәһәр мунчасыныкы күмер ягып эшләтелә, калганнары - мазутта. Хәзерге вакытта элеватор котельнясын газга күчерү эшләре бара, СПТУ котельнясында да газ яга торган 6 казан монтажлана. Котельняларның ягулык белән тәэмин ителү мәсьәләсе әлегә кискен тора, чөнки бүген барысы тик ике - НГДУ БПОсы һәм ит комбинаты котельняларының гына мазутка фондлары бар, калганнарында мәсьәлә ачык кала килә. Өстәвенә, Норлат җылылык челтәре предприятиесе котельнялары хезмәттәннән файдалана торган предприятиеләр һәм оешмаларның бурычлары 10 миллиард сумга якынлашып килү сәбәпле, предприятие үзе дә газ өчен түли алмый һәм бу котельняларның вакытында эшли башлаячагын шик астына куя. Шуна күрә дә утырышта котельняларның резервта башка төр ягулык запасы да булырга тиешлегенә басым ясалуы очраклы түгел иде. Ә инде җылылык челтәре предприятиесе исә бурычлы предприятиеләрне «авызлыклауның» яңа сезонда аларның промышленность базаларына җылылык бирмәүдән дә башка юлын күрми әлегә. Монда сүз беренче чиратта 1995 елдан бирле җыела килә торган бурычы инде бер миллиард сумга якынлашкан МСО, өч еллык бурычы 300 миллионнан артканТатагропроммехмонтаж» ПМКсы, 200 миллион сумнан күбрәк әҗәтле «Надежда» дәүләт предприятиесе, бурычлары чагыштырмача азрак булган илледән артык башка кулланучылар турында бара.

Билгеле, җылылык челтәре предприятиесе материал һәм акча кытлыгы никадәр кыен гына булса да, үз хуҗалыгын чираттагы ягу сезоныны әзерләү буенча шактый күп эш башкарган. Алда әйткәннәрдән тыш, биредә җылылык трассаларын изоляцияләүгә зур игътибар бирелгән. Былтыр шактый гына җылылык торбаларының цинкланган калай белән төрелгәнлегенә игътибар иткән идек инде, быел бу эш тагын ярты километр арада уздырылган. Моннан тыш бер чакрым ярым трассаның изоляциясе өлешчә алыштырылган. Болар һәммәсе аларда җылылык югалуны норматив дәрәҗәсенә калдыруга булышлык итәргә тиеш.

Шул ук вакытта трассаларның җылы кулланучылар балансындагы өлешләренең торышы борчу тудыра. Утырышта белдерү белән чыккан җирле үзидарә Советы члены, җылылык челтәре предприятиесе директоры Р.Г.Хәсәнов билгеләп үткәнчә, аларның 80 процентлабы рәтләп изоляцияләнмәгән һәм бу күпме җылылыкның әрәмгә китүенә сәбәп булып тора. Шуна күрә дә җылылык челтәре предприятиесе хәзер котельняларда җылылык исәпләгечләр куя башлаган. Бу берочтан трассалардан су алуны да чиклән дип уйланыла. Шулай булгач, кулланучы предприятиеләр трассаларның үзләре карамагындагы участокларын ягу сезоны башланганчы тәртиккә китереп, акт буенча тапшырырга тиешләр. Кызганычка каршы, әлегә кадәр ике балалар бакчасыннан кала бер генә предприятие яки оешманың да моны эшләгәне юк. Җылылык хуҗалыгын яңа сезонга әзерләү буенча җирле үзидарә Советы әле майда ук 17 пунктта торган чаралар планы эшләп житкергән булса да, аларның әлегә 6 сы гына үтәлгән, ә МСО, РСУ,геофизика, НУРБ, элеватор һәм шикәр заводы бу эшләргә керешмәгәннәр дә. Югыйсә, МСОның, МППның кайбер йортларына керә торган трассалар авария хәлендә, кичке мәктәпнең үз участогы әзер түгел. Промышленная урамының җөп ягындагы трассасы да кичекмәстән алыштыруны таләп итә. Тиешле техник шартларны үтәмичә, законсыз рәвештә сузылган ул трассадан РСУның 9, машина төзү заводының икешәр газ хуҗалыгы белән, шикәр заводының берәр йорты җылытыла. Сүз унаеннан әйткәндә, яңа төзелгән объектларны тапшырганда аларны җылылык челтәренә тоташтыруның техник шартларын үтәмәү соңыннан бик аяныч хәлләргә китерергә мөмкин. Әле менә төзелеп бетеп килә торган балалар музыка мәктәбе белән дә хәл шундый ук.

Тагын бер мөһим мәсьәлә. Хәзер «Сельхозтехника» котельнясыннан җылытыла торган йортларны Норлат җылылык челтәренең машина төзү заводындагы котельнясына тоташтыруга әзерлек эшләре бара һәм бу ул йортларны җылылык белән тәэмин итүне яхшыртыр дип өметләнергә була. Ә менә СПТУ котельясын газга күчерү эше мона катнашырга тиешле оешмалар, бигрәк тә МСОның битарафлыгы аркасында бик сонга калырга мөмкин. Берочтан, табигый газ кертелгән шәхси йортларны автоном җылылык системасына күчерү зарурлыгы да житди мәсьәлә булып тора.

Утырышта югарыда телгә алынган предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләрен җылылык хуҗалыгында булган житешсезлекләрне җылылык трассаларына су җибәреп караганчыга кадәр бетерергә мәҗбүр иткән карар чыгарылды. Ә суны атна ахырында бирү күздә тотыла.

Р.МУЛЛИН.

Сауганыннан бигрәк сатканы мөһим

Без сөт житештерүнең торышы турында гадәттә көнлек савым күрсәткечләреннән чыгып фикер йөртәбез. Әмма сөт муллыгын ин ачык чагылдыручы бер күрсәткеч бар - сөт - май комбинатына кергән продукция күләме.

Җәй ахырында савымның кимүгә баруы райондагы күпчелек хуҗалыклар өчен элек - электән гадәти күренешкә әверелгәнгә күрә, быел да августта сөт саву һәм аны дәүләткә сатуның азая төшүен ин элек шушы традицион сәбәпкә сылтау күзәтелә. Әмма мәсьәләнеңасылына керешкәндә әлегә сөт кимүгә объектив сәбәпләр юк икәнлеге ачыклана. Сөт хәзерләүдә элеккечә үк тотрыклы эшләүче хуҗалыклар үрнәге дә моны ачык раслый. Әйтик, август уртасыннан бүгенгәчә күрсәткечләрне анализлаганда «Киекле», «Якты Күл» хуҗалыкларында сөт хәзерләүне 18 - 27 центнерга арттыруларын, «Алга»,«Таң»да, РСУның ярдәмче хуҗалыгында да арттыра төшүләрен күрергә мөмкин. Әменә «40 лет Победы», Мичурин исемендәге, Хафизов исемендәге хуҗалыкларда, «Агрохимсервис»ның ярдәмче хуҗалыгында сөт сатуны, киресенчә, 23,5 - 37,9 центнерга киметтеләр. «Игенче», «Әлмәт» хуҗалыкларыннан, шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгыннан да сөт - май комбинатына продукция керү 16,6 - 18,7 центнерга азайган.

Арада ин зур чигенеш Хафизов исемендәге хуҗалыкта. Моңа гаҗәпләнәсе дә юк. Хуҗалыкның Аксумла фермасында, мәсәлән, соңгы вакытта малларны ашату үзагымына куелган дияргә мөмкин. Дөрес, концентрат азыкка кытлык юк, әмма сусыл азыкларны маллар туйганчы ашарлык бирелә дип булмый. Кырдан урып ваклап кайтарыла торган һәм көннәр коры торганга инде шактый ук кипшенгән кукуруз да үзвакытында һәм житәрлек китерелми. Моны Ерепкино белән бергә ике фермага бер генә трактор хезмәт күрсәтү белән аңлатырга тырышалар. Әмма төп сәбәп бу эшнең тиешле контрольгә алынмавында. Ферма мөдире җәйге лагерьда эшнең үзагымына куелуы белән ризалашкан, зоотехник та бирегә бик сирәк кенә килеп чыккалый. Шулай булмаса, мондый коры көннәрдә дә малларның әчәр су белән дә житәрлек тәэмин ителмәвен, ин гади нәрсә - тоз мәсьәләсенең дә хәл кылынмавын ничек аңлатасын, лагерьның бер почмагына таш күк каты берничә тоз кисәге кую гына маллар турында кайгырту дигән сүз түгел бит әле? Кырлар тулы салам яткан вакытта аны лагерь янына берәр генә йөк кайтарып куюны да проблемага әйләндергәч, нинди сөт муллыгы турында сүз алып барасың ди инде? Озакламый савым көтүен тулыландырырга тиешле буаз таналар исә бу фермада бөтенләй үк язмыш иркенә куелган дисәк тә әллә ни арттыру булмастыр. Аларына Ерепкино фермасында да игътибар житеп бетми. Шуна күрә бу хуҗалыкта мөгезле эре терлекләрнең тәүлеклек артымы августта 334 грамм гына булуы гаҗәп тә түгел.

Кызганычка каршы, мондый мисалларны башка кайбер хуҗалыклардан да китерергә мөмкин. Әйтик, сөт - май комбинатының ярдәмче хуҗалыгында сыерларны азыктан өзмәсәләр дә, алларында тоз юк, буадан эчертүгә сылтап, өстәмә су кую турында да уйламыйлар. Ин гаҗәбе шул, район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең җаваплы кешеләре күп кенә хуҗалыкларда сөтне арттыруга, һич югы киметмәүгә хезмәт итәргә тиешле таләпләрнең ин гадиләре дә үтәлеп житмәвенә тап булалар һәм моны урыннарда да таныйлар. Димәк, сөт муллыгына ирешергә телибез икән, бу тармакны көндәлек игътибар үзәгендә тотмыйча мөмкин түгел.

А.УХВАНЬКОВ,
район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең терлекчелек бүлеге башлыгы.
Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ,
безнең корреспондент.



Тракторчы Юныс Якуб улы Фәсхетдиновны «Чирмешән» күмәк хуҗалыгында белмәгән кеше юктыр. Хуҗалыкның ин тырыш, алдынгы механизаторларыннан берсе ул. Гомерен техникага игенчелеккә багышлаган кеше. Егерме икенче елын чылбырлы тракторда. Иртә яздан кара көзгәчә кырлардан кайтып керми. Сөрү, чәчү кебек тырышлык, тәҗрибә таләп итә торган эшләрне хуҗалыкта елның - елында Юныс Фәсхетдиновка һәм хезмәт юлларын аның белән бер чорда башлаган Рияз Гыйләҗев белән Азат Вәлиәхмәтовка ышанып тапшыралар. Ә көзен Юныс чөгендер казыгу комбайнына күчеп утыра. Биредә дә үзен эшенең остасы итеп таныгты ул. Районкүләм сабанчылар ярышында катнашуны да аңа ышанып йөклиләр. Гаиләсендә дә тәртип. Мәктәптә укытучы булып эшләүче хатыны Гөлсинә белән бер кыз үстерәләр. Бу көннәрдә тракторчының вакыты аеруча тыгыз. Башта уҗым культуралары чәчү өчен җир хәзерләүдә эшләде, чәчүне дә ул башкарды.

Ж.ШАКИРОВ.
Н.КВАШНИНА фотосы.

ФАЙДАЛЫ ДА, ЭЧТӘЛЕКЛЕ ДӘ

Колбай Мораса урта мәктәбендә укучыларның җәйге ялын файдалы һәм эчтәлекле итеп үткәрү буенча бай тәжрибә тупланган һәм ул елдан - ел тулылана бара. Быел ул балаларны Халыкара яклау көне - 1 нче июньне бай программа буенча үткәрүдән башланды. Бу көнне ярты төнгәчә балалар өчен төрле спорт уеннары, ярышлар, дискотека үткәрелде. «Алга» КХАсы ярдәмендә чәй өстәле әзерләнде. Шул көннән күтәренке кәеф белән ялга таралышкан балаларны җәй буе байтак мавыктыргыч шатлыклар көтә иде. Алар арасында Болгарда III нче республика балалар форумында катнашу, борынгы Биләрнең тарихи урыннарына, Хужалар тавына баруиде. Әлеге чараларның һәммәсе балалар күнелендә онытылмас хатирәләр калдырырлык эчтәлекле, тәрбияви булды. «Кояшкай» мәктәп балалар мәйданчыгы да кече яшьтәге балалар өчен күп күнелле мизгелләр бүләк итте.

Билгеле, балаларның файдалы хезмәттә катнашуы турында да кайгырттык. Балалар хезмәте белән мәктәп бакчасында мул итеп яшелчә, жиләк - жимеш үстерелде, алар кышкылыкка мәктәп ашханәсе өчен тозлап - киптереп куелды, саклауга салынды.

Җәйге каникул шулай балалар өчен чын ял, көч жыю чоры булды, алар укуда да сынатмаслар дип уйлыйбыз.

Р.БОРһАНОВА,
мәктәпнең класстан тыш эшләрне оештыручысы.

ПЕНСИОНЕРЛАР ДА ЧИТТӘ КАЛМЫЙ

Урактан беркем дә читтә калмый бездә. Әнә, елның - елында ындыр табагы мәдире булып эшләүче пенсионер Әнәс Камалов быел да биредә хезмәт куя. Үлчәүче Фоат Сәүжиһанов та пенсионер. Икесе дә үз вазифаларын жиренә житкереп үтиләр.

Операторлар Алиф Мәхмүтов, Илсур Сафин, Илшат Нәбиуллин, Әмир Шәрәпов та тырышалар.

Ындыр табагында эш өч сменада оештырылган. Хатын-кызлар, ә алар арасында пенсионерлар да, укытучылар да, укучылар да бар, барысы да ашлык эшкәртү белән мәшгульләр. Алар өчен эш фронты бер дә бетеп тормый: ашлык фуражга салына , орлыкка бүленә, дәүләткә дә озатыла.

Шоферлар Фәнис Фәссахов, Сәлим Нәбиуллин исә бу көннәрдә көне - төне ындыр табагында булалар: биредә ашлык күчерү белән мәшгульләр алар.

С.ФӘТХЕТДИНОВА,
хәбәрче.
Яңа Әмзә авылы.

Н.АЗИЗОВ фотосы.

Норлат шәһәрендә яшәүче әниебез НУРИЯ ХАҖЕТДИНОВАГА 2нче сентябрьдә 50 яшь тула.

Аңа озын гомер бирсен ходай,
Кояш сиңа бирсен яктылык.
Балаларың гына түгел, оныкларың да
Китерсеннәр сиңа яхшылык.

Эдуард, Зөлфия, оныкларың, кодаларың.

БЕЛДЕРҮЛӘР

Сатабыз

Әйбәт хәлдәге, 1987 елда чыккан ВАЗ - 2109 автомашинасы. **2 - 13 - 14 телефоны буенча кичке 7дән соң мөрәҗәгать итәргә.**

***

Төзелеш материаллары белән 10 х 10 үлчәмле өй бурасы. Бәясе килешү буенча. Адрес: **Чирмешән районы, Иске Кади авылында Камалов Хәлилгә мөрәҗәгать итәргә.**

***

Т - 40 тракторы, документлары һәм номеры тиешле хәлдә, вариантлар булуы мөмкин. **Чаллы Башы районы, Сов.Норлат авылында Маняпов Илдарга мөрәҗәгать итәргә.**

***

8 х 11 үлчәмле өй бурасы. **Зирекле авылында Әхмәтов Рамилгә мөрәҗәгать итәргә.**

***

«ИЖ - Планета - 5» мотоциклы. **Тел.: 5 - 18 - 60, кичке 5тән соң.**

***

1992 елда чыккан ВАЗ - 21043 автомашинасы. Бәясе 23 млн. сум. **Тел.: 2 - 26 - 95.**

***

Туй күлмәкләре. Комплекты белән фата, перчаткалар. Бәяләре 500 мең сумнан алып 1200 мең сумга кадәр. **Чапаев ур., 19 нчы йортка мөрәҗәгать итәргә.** Б 97 серияле лицензиянең номеры 054281.

Алмаштырабыз

Каралты - куралары, мунчасы белән шәхси йорт ике бүлмәле фатирга. Адрес: **Южная ур., 40, теләсә кайсы вакытта мөрәҗәгать итәргә.**

***

Лермонтов урамында 36 нчы йорт бер яки ике бүлмәле фатирга.

Төрлесеннән

Ике яшьтән олырак кызыл төстәге ат югалды. Күргән кешеләрнең **Түбән Чаллы авылында Герасимов Николайга хәбәр итүләрен сорыйбыз.**

***

Рәҗәпов Гомәр Госман улы исеменә 1997 елның 5 нче апрелендә бирелгән ААР серияле 201741 номерлы шофер таныклыгын гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

***

Процент хисабына бурычка акча алабыз. **Тел.: 2 - 22 - 97.**

Гаражлар, йортлар (арзан бәягә) төзибез. Житди булмаган сораулар белән мөрәҗәгать итмәвезне сорыйбыз. **Тел.: 5 - 16 - 25, Нәҗипкә.**

РӘХМӘТ БЕЛДЕРӘБЕЗ.

Тормыш иптәшем, әтиебез Габделәхәт Габделхәй улы Гатинны соңгы юлга озатуда мораль һәм матди ярдәм күрсәткән 547 нче ПМК, элеватор, сәүдә базасы коллективларына, туганнарга, дусларга, танышларга, тирә - күршеләргә олы рәхмәтебезне житкерәбез.

Мәрхүмнең тормыш иптәше, кызы.

БЕЛДЕРҮЛӘР

Норлат жылылык челтәрләре предприятиесе 1997 елның 6 сентябрендә иртәнге сәгать 9да тышкы жылылык челтәрләрен 8 атм. басым белән пресслау үткәрә.

Жылылык белән тәэмин итү системасын зарарланудан саклау һәм бәхетсезлек очраклары китереп чыгармау өчен учреждение, оешма, йорт идарәләре, торак - коммуналь бүлекләре, мәктәпләр, шифаханәләр, балалар бакчалары житәкчеләренә, шәхси йорт хужаларына жылылык системасы һәм су жылыту приборларын ышанычлы итеп сүндерүне тәэмин итү сорала.

Куркынычсызлык максатында эшермәләрне ябарга, каплау приборлары куярга, биналардагы жылылык челтәрләрендә һава керү һәм чыгу юлларын ачарга. Сынаулар вакытында челтәрләрнең торышын контрольдә тоту өчен тиешле күләмдә күзәтүчеләр куярга.

Жылылык белән тәэмин итү системасында зарарлану килеп чыкканда кичекмәстән дежурга хәбәр итәргә. Телефоннар: 2 - 17 - 14, 2 - 23 - 82.

Пресслауга әзерлек турында Норлат ПТСының ПТОсына 2 - 23 - 82 телефоны буенча хәбәр итәргә.

Түбәндәге чараларны үтәмәгән очракта килеп чыккан кимчелекләр өчен жаваплылык жылылык энергиясен кулланучыларга төшәчәк.

Хөрмәтле норлатлылар!

«Девон - Кредит» акционерлык банкы клиентларга хезмәт күрсәтү төрләренен киңәйтә. 2 нче сентябрьдән коммуналь хезмәтләр өчен, шул исәптән, төзелешләрдән, корылмалар һәм биналарга, транспорт чараларына салым, жир салымы, газ, уг, кайнар су, чүп - чар түгүгә Норлат шәһәрендә яшәүчеләрдән түләүләр кабул ителә башлый. Түләү акчалата да, безнең банктагы вкладлар нигезендә дә башкарылырга мөмкин. Бу - исәп - хисапның үзвакытында гамәлгә ашырылуына хезмәт итә һәм түләү срогы узган өчен пеня артуыннан да коткара торган уңай форма. Түләүләр Норлат шәһәре, Совет ур., 179 адресы буенча кабул ителә.

Вкладларның саклылыгы һәм хезмәт күрсәтүнең сыйфатлылыгы гарантияләнә. Сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәләрендә гамәлгә пластик карточкалар керту күздә тотыла. Бу чаралар шул юнәлештәге дәүләт программасы рамкаларында үткәрелә.

Үзара отышлы хезмәттәшлек итүгә өметләнеп, сезне, банкта көтәбез.

***

«Девон - Кредит» АБның Норлат филиалы халык игътибарына «Халык вкладлары буенча процент ставкаларының үзгәрүе турында» хәбәр итә.

Банк идарәсе карары нигезендә 1997 елның 28 августыннан (17 нче беркетмә).

1. 1997 елның 1 сентябреннән яңа кабул ителгән һәм элек ачылган вкладлар буенча өстәмә взносларга түбәндәге төрләр буенча процент ставкаларын үзгәртергә:

- 31 көн саклау вакыты белән сроклы вклад - еллык 7 процент;

- 100 көн саклау вакыты белән сроклы вклад - еллык 10 процент;

- 100 көн саклау вакыты белән пенсия вклады - еллык 14 процент;

- 1 ел саклау вакыты белән сроклы вклад - еллык 8 процент;

- балалар өчен максатчан вклад - еллык 5 процент;

- сорап алганчыга кадәрле вклад - еллык 2 процент.

2. 1997 елның 1 сентябренә кадәр ачылган вкладларның процент ставкалары вкладның срогы беткәнчегә кадәр саклана, аннан соң автоматик пролонгация рәвешендә процентлар гамәлдәге ставкалар буенча исәпләнә (сорап алганчыга кадәрле вкладтан тыш).

3. Вкладлар буенча процент ставкалары үзгәрүе һәм вклад ачу шартлары турында филиал управляющийлары халыкка үз вакытында хәбәр итәргә тиешләр.

4. Бу күрсәтмәнең үтәлеше буенча контрольне халык вкладлары департаменты начальниты урынбасары Г.Т.Дроновка йөкләргә.

Банк президенты З.М.Насыйбуллин.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, жомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хужалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм жәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, жаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2336 данә.